МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.06.2021 г.Казань № 408

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 24 июнендә 7747 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 20 июнендәге 444 номерлы боерыгы белән расланган Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фондыннан тәэмин ителә торган аерым категория хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе Илкүләм гвардия гаскәрләрендә хезмәт узган һәм махсус полиция исеме булган затларның һәм хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән, хәбәрсез килеш монда юк дип танылган) кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре балаларына һәм хәрби хезмәттән (гаскәрләрдә, органнарда һәм учреждениеләрдә хезмәт итүдән) азат ителгәннән соң хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затларның балаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фондыннан тәэмин ителә торган аерым категория хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе Илкүләм гвардия гаскәрләрендә хезмәт узган һәм махсус полиция исеме булган затларның һәм хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән, хәбәрсез

килеш монда юк дип танылган) кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре балаларына һәм хәрби хезмәттән (гаскәрләрдә, органнарда һәм учреждениеләрдә хезмәт итүдән) азат ителгәннән соң хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затларның балаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 20 июнендәге 444 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 04.09.2014 №482, 07.06.2016 №317, 11.07.2016 №398, 08.06.2017 №351, 07.05.2018 №347, 19.09.2018 №887, 15.07.2019 №558, 12.11.2019 №987, 25.03.2020 №193, 13.07.2020 №501, 09.10.2020 №716 боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фондыннан тәэмин ителә торган аерым категория хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе Илкүләм гвардия гаскәрләрендә хезмәт узган һәм махсус полиция исеме булган затларның һәм хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән, хәбәрсез килеш монда юк дип танылган) кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре балаларына һәм хәрби хезмәттән (гаскәрләрдә, органнарда һәм учреждениеләрдә хезмәт итүдән) азат ителгәннән соң хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затларның балаларына ай саен бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.06.2021 №408 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фондыннан тәэмин ителә торган аерым категория хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе Илкүләм гвардия гаскәрләрендә хезмәт узган һәм махсус полиция исеме булган затларның һәм хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән, хәбәрсез килеш монда юк дип танылган) кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре балаларына һәм хәрби хезмәттән (гаскәрләрдә, органнарда һәм учреждениеләрдә хезмәт итүдән) азат ителгәннән соң хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затларның балаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 20 июнендәге 444 номерлы боерыгы белән расланган Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фондыннан тәэмин ителә торган аерым категория хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе Илкүләм гвардия гаскәрләрендә хезмәт узган һәм махсус полиция исеме булган затларның һәм хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт итү бурычларын) үтәгәндә һәлак булган (үлгән, үлгән дип игълан ителгән, хәбәрсез килеш монда юк дип танылган) кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре балаларына һәм хәрби хезмәттән (гаскәрләрдә, органнарда һәм учреждениеләрдә хезмәт итүдән) азат ителгәннән соң хәрби җәрәхәт аркасында үлгән затларның балаларына ай саен бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Айлык пособие билгеләү өчен мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе Саклык банкының (филиалында, структур бүлекчәсендә) оешмасында федераль законнар нигезендә социаль түләүләрне алу өчен ачылган счет реквизитларын яки яшәгән урыны буенча адресын күрсәтеп, гариза (гариза формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән) тапшыра, аңа түбәндәге документлар теркәлә:

а) чит ил дәүләте территориясендә бирелгән, баланың Россия Федерациясеннән читтә көндезге формада белем алуынраслый торган документ күчермәсе һәм аның рус теленә күчермәсенең нотариаль таныкланган күчермәсе (һәр уку елында 18 яшен тутырганчы тапшырыла) – Россия Федерациясеннән читтә белем алу учреждениесендә көндезге формада белем алучылар өчен;

б) баланың әтисен хәрби хезмәткә чакыруны һәм хәрби хезмәткә чакырылу урыны буенча хәрби комиссариат тарафыннан бирелгән чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтүне раслаучы белешмә;

в) чакырылыш буенча хәрби хезмәт бурычларын үтәгән вакытта хәрби хезмәткәрнең вафат булуын (билгеләнгән тәртиптә хәбәрсез югалган дип танылуын яки үлгән дип белдерелүен) раслый торган документ күчермәсе яки хәрби хезмәткәрнең (хезмәткәрнең) үлеменә китергән җәрәхәт яисә авыру белән хәрби травма арасындагы сәбәпчел бәйләнеш турында хәрби-табиблык комиссиясе бәяләмәсе күчермәсе;

г) чит ил дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе.

д) граждан хәле актларын теркәү органы яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениесе тарафыннан бирелгән уллыкка (кызлыкка) алу турында таныклык күчермәсе;

е) чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән вафат булуны дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсен һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе.

Әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы дүртенче абзацта күрсәтелгән балаларга айлык пособие билгеләү турындагы гаризага әлеге пунктның документлары, «б» һәм «в» пунктларында күрсәтелгән документлар урынына контракт буенча хәрби хезмәт үтәгәндә (хезмәт бурычларын башкарганда) хәрби хезмәткәрнең (хезмәткәрнең) һәлак булуын (үлемен, билгеләнгән тәртиптә билгесез рәвештә юкка чыгуын тану яки үлгән дип игълан итү турында) раслаучы документ күчермәсе теркәлә.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан таныклана.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гариза белән аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интер-

нет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча вәкаләтле органнардан түбәндәге документлар һәм түбәндәгеләрне раслый торган белешмәләр алына:

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

вафат булуны дәүләт теркәвенә алу турында;

гомуми белем алу оешмасында, һөнәри белем оешмасында көндезге формада белем алу турында, – белем алу учреждениесендә көндезге формада белем алучылар өчен;

туендыручыны югалту очрагы буенча пенсия алу, балачактан инвалидлык билгеләнүе турында, – 18 яшькә җиткән бала өчен;

балага опека (попечитель) билгеләнүе турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

инвалидның, шулай ук хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт бурычларын) үтәгән вакытта яралану, контузия алу, гарипләнү яки авыру нәтиҗәсендә зыян күргән затның үлем сәбәбе турында «хәрби травма» тәгъбирләнеше белән бәяләмә.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Идарә (бүлек) мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торганын да, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш

тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш».

3.4.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Идарә (бүлек) белгече вәкаләтле органнардан электрон формада түбәндәге документларны һәм белешмәләрне ала:

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

вафат булуны дәүләт теркәвенә алу турында;

туендыручыны югалту очрагы буенча пенсия алу, балачактан инвалидлык билгеләнү фактын раслый торган, – 18 яшькә җиткән бала өчен.

Айлык пособиене билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Идарәдә (бүлектә) булмаганда, Идарә (бүлек) белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы аша вәкаләтле органнарга түбәндәге белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

вафат булуны дәүләт теркәвенә алу турында;

балага опека (попечитель) билгеләнүе турында;

инвалидның, шулай ук хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт бурычларын) үтәгән вакытта яралану, контузия алу, гарипләнү яки авыру нәтиҗәсендә зыян күргән затның үлем сәбәбе турында «хәрби травма» тәгъбирләнеше белән бәяләмә;

туендыручыны югалту очрагы буенча пенсия алу, балачактан инвалидлык билгеләнү фактын раслый торган, – 18 яшькә җиткән бала өчен;

шәхси счетның иминият номеры турында;

гомуми белем алу оешмасында, һөнәри белем оешмасында көндезге формада белем алу турында, – белем алу учреждениесендә көндезге формада белем алучылар өчен.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон формада алынган мәгълүматлар, мәгълүмат бирү турында вәкаләтле органнарга юлланган рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

3.8.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.1. Идарә (бүлек) белгече:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы);

айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерә;

айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны имзалау өчен Идарә (бүлек) җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Идарә (бүлек) җитәкчесенә имзалау өчен юлланган айлык пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.».